# Татар халык бәйрәмнәре

Халык бәйрәмнәре — шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе, һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хисләр культурасын тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар.

Бәйрәмнәр халык тормышының, культурасының аерылгысыз бер элементы да булып торалар.

Халык бәйрәмнәре — шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы да. Эш шунда, ул бәйрәмнәрдә халыкның олысы-кечесе актив катнаша, һәр буын кешесе бәйрәмдә катнашу тәртибен гадәт, традиция рәвешендә, ана сөте белән дигәндәй, үзенә сеңдерә. Бәйрәм «вазифалары» теләп, шатланып үтәлә. Шулай итеп, һәр кеше үзе дә сизмәстән үзара аралашу, үз-үзеңне тоту гадәтләрен үзләштерә, тәрбияләнә.

Халык бәйрәмнәре һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, чөнки җыр, бию, яңа көйләр башкару, очрашу-танышулар шушы көннәрдә була. Алар аны кайда гына булса да — үз авылына, төбәгенә тартып тора.

Халык бер милләт булып оешканда уртак бәйрәмнәр системасы барлыкка килә. Чыннан да, татар халкы милләт булып оешкан вакытта, әйтик, казан татарларының сабантуй бәйрәме ут күршеләре булып киткән мишәрләр арасында да тарала барып, әкренләп гомумхалык бәйрәменә әйләнгән.

Халык бәйрәмнәре милли хисләр формалашуга, аларның культурасын, милли горурлык тәрбияләүгә ярдәм итәләр, шул ук вакытта алар милли хисне канәгатьләндерүдә, гамәлгә ашыруда нәтиҗәле чара да булып тора.

Традицион бәйрәмнәр мирасы килеп чыгышы, тамыры төрле булган элементларны туплау һәм үзләштерү юлы белән барлыкка килгән. Иҗтимагый-экономик шартлар үзгәргәндә, аерым очракларда исә дәүләт дине алмашынганда, бәйрәм культурасы да алмашынган. Ләкин бу алмашыну беркайчан да абсолют булмаган, иске бәйрәмнәрнең аерым гамәлләре, йола-ритуаллары, атрибутлары һ. б. рәсми хакимиятләрнең һәм руханиларның катгый тыюына һәм эзәрлекләвенә дә карамастан, яңа заман бәйрәм культурасына керешеп киткәннәр.

Ни өчен шулай булган соң? Монда иң мөһим сәбәп аерым иҗтимагый күренешләрнең, хосусан гореф-гадәтләрнең, тотрыклы һәм ныклы булуында. Чөнки алар гасырлар буе тәрәккый иткәннәр, үзгәреп тора торган шартларга җайланып камилләшкәннәр, шомарганнар. Шул рәвешле бу гореф-гадәтләрнең күбесе үз-үзеңне тотуда уңайлы һәм күнегелгән зарури бер кагыйдәгә үрнәккә әйләнгән.

***2 Төп өлеш: Татар халык бәйрәмнәре һәм йолалары***

## Нәүрүз бәйрәме.

Бу сүзнең мәгънәсе фарсыча «яңа көн» дигәнне аңлата. Урта Азиядә, Иранда, Әфганстанда һәм кайбер башка илләрдә бик борынгыдан килгән Яңа елны каршылау бәйрәме ул. Нәүрүз көн белән төн тигезләшкән чорга—21—22 мартка туры килгән. Әлеге төбәкләрдә язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул.

Безнең ата-бабаларыбыз, төрки халык буларак, әлбәттә, Нәүрүзне белгәннәрдер. Һәрхәлдә, Яңа елны март аенда башлап җибәрүнең татарлар яшәгән Урта Идел буенда булганлыгы мәгълүм. Ләкин ул вакытта халыкның аны ничек бәйрәм иткәне, аянычка каршы, безгә билгесез әле. Дөрес, XIX гасырга караган мәгълүматлар бераз бар. Ул чорда Нәүрүз көннәрендә (ул берәр атнага —10 көнгә сузылган) йорттан-йортка кертеп «нәүрүз әйтеп» йөрү гадәте булган. Моны укучы балалар — шәкертләр башкарган. Нәүрүз такмагын укып, яки яттан әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр.

Шәкертләрнең болай йөрүләре үзенә күрә бер күңел ачу була. Салкын кышлар бетеп килүенә шатлану, авыл халкының күңелен күтәрү. Бераз сыйланып алучылар да күзәтелгән, чөнки нәүрүз әйтүләр беркайчан да бушка булмаган. Алар күчтәнәч, акча таләп иткәннәр:

Ач ишегең,керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер-дога кылабыз,
Аш-сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәкбад.

Һәм башка шундый такмаклар дәвам иткән.

Нәүрүз такмаклары Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри тарафыннан язылып алынганнар. Фольклорчылар язып алган төрле вариантлар бастырып та чыгарылды. («Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары».— Казан, 1980.) Тулырак тексты «Нәүрүз бәете» исеме белән «Борынгы татар әдәбияты» китабында басылып чыкты (Казан, 1963).

Әйтергә кирәк, нәүрүз такмагы төрлелеге белән аерылып торган. Еш кына шәкертләр, үз авыл халкына җайлаштырып, аларны үзләре үк уйлап чыгарганнар.

. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, нәүрүз әйтеп йөрүләр авыл саен ук булмаган. Булган хәлдә дә халык бәйрәме формасын ук алмаган. Моның сәбәбе, минемчә, Яңа елны март аенда башлап җибәрү гадәте юкка чыгуда. Чөнки Казан ханлыгы Рус дәүләтенә буйсындырылганнан соң аны христиан календаре буенча 1нче гыйнварга күчергәннәр. Ә дини бәйрәмнәрне элеккечә ислам календаре буенча билгеләү дәвам иткән.

Халкыбызның традицион бәйрәмнәрен җентекләп өйрәнү шуны күрсәтә: Яңа елны мартта каршы алу бәйрәменең (Нәүрүзнең) аерым күренешләре, элементлары бераз кичектерелгән һәм башка халыкларда яз килүне каршылаган

кебек үк, безнең җирлектә дә чын мәгънәсендә яз килү вакытына күчкән. Чөнки «яз» дигән төшенчәне халыкның үзенчә кабул итүе билгеле. Беренче тамчылар, әлбәттә, яз башлану билгесе. Әмма бәйрәм итәргә иртәрәк әле — салкын да, пычрак та. Чын мәгънәсендә халык бәйрәме итеп үткәрү өчен иркен мәйдан, җир кибә төшеп, яшел үлән күренә башлагач уңайрак бит.
Шуңа күрә, башка халыкларның нәүрүзләре кебек үк, безнең җирлектә дә нәкъ менә язгы чәчүгә чыгу алдыннан үткәрелә торган бәйрәм барлыкка килә.

## Сабантуй бәйрәме.

Сабантуй — элек-электән халкыбызның һәрчак яратып, зур күтәренкелек белән үткәрә торган олы бәйрәме ул. Күреп үткәнебезчә, халык йолаларын өйрәнүче этнографлар да аның белән күптән кызыксынганнар, ләкин аларның төп игътибары нигездә мәйдан өчен бүләк җыю тәртибенә һәм мәйданның үзенә, аннары җиңүчеләрне бүләкләү мизгеленә юнәлтелгән. Язгы йолалар исә сабантуй белән бәйләнештә каралмаганнар, аның белән берлектә өйрәнелмәгәннәр. Хәлбуки, соңгы вакыттагы тикшеренүләр сабантуйның иртә яздан башлап үткәрелә торган тулы бер йолалар, күңел ачулар, ярыш-бәйгеләр тезмәсе икәнлеген исбат итәләр. Алар язын кар эреп җир ачыла башлаган көннәрдән алып язгы чәчүгә кадәр үткәрелгән. Моннан тыш, бу бәйрәмнең башка үзенчәлекләре дә бар. Аны үткәрү өчен төгәл билгеләнгән календарь көн генә түгел, атнаның аерым көне дә юк. Монда бөтенесе елның нинди булуына, карның ничек эрүенә һәм җирнең чәчү өчен ни дәрәҗәдә әзер булуына бәйле. Моны, кагыйдә буларак, авыл картлары киңәшеп хәл кылганнар һәм бәйрәмне үткәрү көне турында базар көнне игълан иткәннәр. Шуның белән бергә, бер төбәктәге авыллар ярышларны (бәйрәмнең иң югары мизгелен — мәйданын) төрле көнне үткәрергә омтылганнар. Бу башка авыл кешеләре дә күршеләренең бәйрәмендә катнаша алсын өчен шулай эшләнгән. Ләкин сабантуй ул шул авыл халкының үз бәйрәме исәпләнгән һәм бәйрәмгә башка авыллардан кунак чакыру гадәте булмаган. Катнашасы килгән күршеләр чакырмыйча гына, мәйданга үзләре килгәннәр һәм бәйгеләр төгәлләнгәч, гадәттә өйләренә кайтып киткәннәр.
Бәйрәмдә ярышлар гасырлар буена килгән тәртип буенча үткән.Аларны ат чабышы башлап җибәргән.Ат чабышлары аеруча абруйлы саналган,шуңа күрә булдыра алган һәр кеше аты белән чабышта катнашырга омтылган.Атларга 8-12 яшьлек малайларны атландырганнар.Ярыш түбәндәгечә үткән.Катнашучылар,бергә җыелып,авылдан гадәттә 5-8 чакрым ераклыктагы старт урынына киткәннәр.Чабышка җитәкчелек итүчеләрнең берсе алар белән бергә барган.Аның сигналы буенча җайдаклар басу юлыннан авылга,мәйданга табан,ягъни финишка элдерткәннәр.
Сабантуй бәйрәмендә кичләрен яшьләр уены аның аерылгысыз өлеше булган.Бу уеннар йомырка җыю көненнән башланып,берничә көн дәвам иткән.Мәйдан көнне андый уеннар үткәрү мәҗбүри исәпләнгән.Уенны я мәйдан булган җирдә,я үкенечәдә,болында,аланлыкта традицион урында үткәргәннәр.Яшьләр уенга киенеп-ясанып килгәннәр,бу көнне аларның әти-әниләре дә күңел ачуларына каршылык күрсәтмәгән.Төн урталарына тикле гармун,скрипка тавышы яңгыраган;егетләр һәм кызлар әйлән-бәйлән уйнаганнар,биегәннәр,җырлаганнар.Җырлы-биюле уеннар аеруча күп һәм төрле булган.


Әнвәр
ШӘРИПОВ

САБАНТУЙЛАР ЖИТСӘ

Сабантуйлар житсә, күңелләрем
Яшел аланнарга ашкына..
Язгы чәчәкләрнең хуш исләрен
Иснәп туя алмыйм һич кенә.

Сабантуйлар житсә, күңелләргә
Шатлык хисе, жыр һәм моң тула.
Түзә алмый йөрәк читлегендә,
Ерак–еракларга омтыла.

Сабантуйлар житсә, яшьлек хисе
Үтеп керә барлык йортларга.
Күрәш дәрте белән яна башлый
Житмеш–сиксән яшьлек
картлар да.

Сабантуйлар житсә, горурланам,
Чиксез көчен күреп халкымның.
Илтер халкым ерак гасырларга
Сабантуйлар биргән ялкынын.

## Жыен бәйрәме.

.

*Жыен* дигән исем чынлыкта халык бәйрәмнәрен генә түгел, бәлки яшьләр уенын да, уңайлы вакытта өйләрдә җыелып, үлгәннәрне искә алу мәҗлесендә Коръән укуны да колачлый. Бу очракта без Казан татарларында яшәп килгән халык бәйрәме — җыенга анализ ясауны күздә тотабыз.

Бәйрәмнең төп үзенчәлекләрен күрсәтик. Ул җәйге вакытта, язгы чәчү эшләре бетеп, печәнгә һәм уракка төшкәнче үткән. Җыенны традициядән килгән билгеле бер вакытта берничә авыл бергә үткәргән. Икенче атнада башка «даирә» авыллары бәйрәм иткәннәр, һәм бәйрәмнең чираты да традицион булган.

. Анализ күрсәткәнчә, җыен күпчелек очракта авыллардан берсенең — гадәттә иң борынгы авыл исеме белән атап йөртелгән.Кайбер җыеннар бәйрәм үткәрелә торган урын исеме белән аталган, ягъни топонимнар һәм гидронимнар (елга-күл исемнәре) белән бәйле булган. Андыйларга, мәсәлән, «Кала тау җыены», «Биек тау җыены», «Яссы болын», «Куш Капка», «Казы», «Базы җыены» (Бөре өязендәге елга исеме буенча) керә.

Кайчагында бәйрәм исемендә җыен сүзе бөтенләй әйтелмәгән. Мондый күренеш башлыча Тәтеш өязе өчен характерлы. Анда түбәндәге атамалар йөргән: «Шыкма», «Чабыр», «Куш Капка», «Кәлти», «Җуа», «Каравыл тавы» һ. б. Күрәбез ки, алар конкрет бер авыл исеме белән түгел, бәлки нигездә топонимнар һәм оронимнар белән бәйләнгән. .

Җыеннарның аз санлы бер өлеше христиан дине бәйрәмнәре исеме белән: *Микола җыены* (Никола — Иске стиль буенча 9 май), *Тройча җыены* (Троица), *Тике җыены* (Тихон яки Тихвинская божья матерь) һ. б. аталган.

Инде әйтеп киткәнебезчә, бәйрәм билгеле бер авыллар группасында, шул даирә өчен төгәл билгеләнгән вакытта — июнь ае башыннан алып 4—6 атна эчендә үткәрелгән. Шулай итеп, ул авыл хуҗалыгы эшләреннән чагыштырмача буш вакытка туры китерелгән. Вакытның төгәл билгеләнгән (беркетелгән) булуы дигәндә без теге яки бу календарь датаны күздә тотмыйбыз, чөнки дата (көн) төрле булган, ә бәйрәмне үткәрү вакыты табигатьтәге фенологик үзгәрешләргә бәйле булган. Җыен вакытын күрсәткәндә информаторлар, мәсәлән, «арыш серкә очырганда», яки «сыерчык бала очырганда» дип ачыклап әйттеләр. Бәйрәм итү чираты да билгеләнгән булган, җыенны билгеле бер авыллар даирәсе башлап җибәргән, икенчесе дәвам итеп киткән һәм, ниһаять, өченчесе җыен бәйрәмнәрен төгәлләгән. Шуңа күрә махсус сөйләшеп килешенүләрнең вакыты турында искәртеп торуларның кирәге булмаган — авыл халкы үзенең *бәйрәм атнасын* яхшы белгән һәм аңа алдан ук хәзерләнә башлаган. Авылны тәртипкә китерү, чистарту һәм җыештыру бәйрәмгә әзерлекнең мәҗбүри шарты исәпләнгән.

Бу бәйрәмнең икенче бер үзенчәлеге шунда булган: җыеннарын бу атнада бәйрәм итмәгән башка авыл кешеләре кунакка килгәннәр күчтәнәч алып килгәннәр.

## Каз өмәсе.

Көзге-кышкы күмәк йолалар һәм бәйрәмнәр арасында *өмә* аерым бер урын тота. Крестьян хуҗалыгында өмәләр ашлык сугу, утын әзерләү, бура күтәрү һ. б. кебек аеруча авыр һәм зур эшләрне кыска вакыт эчендә башкарып чыгу өчен үткәрелгән.

Безнең борынгы әби-бабайлар казны бик яратканнар. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясаганнар. Билгеле булганча, мендәр өеменнән башка татар йортын күз алдына китереп тә булмый. Икенчедән, каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдалана белгәннәр, шулпасын да яратып ашаганнар. Күп төрле каз ашлары турында әйтәсе дә түгел; каз бәлеше, каз коймагы, каз тәбикмәге, каклаган каз... дисеңме. Җәй көннәрендә кипкән каз ите белән ит юклыгы да бик сизелмәгән. Каз маен хәтта дәвалау өчен саклаганнар: кышкы суыкларда бит, колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр.

Инде борынгыдан калган йолаларга килсәк, анда каз билгеле бер урын алып торган. Улы яки кызының үз тормышын корыр вакыты җитсә, ана кеше берничә казын туйга дип саклап тоткан. Чөнки пар каз — ул туйның хөрмәтле күчтәнәче. Матур табакка салып казны туй мәҗлесенең түренә чыгарганнар. Аны җиренә җиткереп, йолаларын үтәп бүлә белә торган үрнәк

тормышлы мөхтәрәм осталар булган. Каз күтәреп килгән «күчтәнәчле кунак» башка вакытта да, гадәттә, аерым хөрмәткә лаек саналган.

Каз өмәләре авыл тормышының күренекле вакыйгасы булган.Аны бигрәк тә кызлар көтеп алганнар.Каз өмәсеннән читтә калмас өчен алар бәбкәләре күп булган апаларга җәйдән үк сүз салып куйганнар.Бу гаиләгә охшарга,ярарга тырышканнар,йорт эшләрендә,ә кайчак урак эшендә дә ярдәмләшкәннәр.Каз өмәсе-ул,иң элек,матур итеп аралашу,күңел ачу,үзеңне күрсәтү чарасы.Кыз кешегә кияүгә дә чыгасы бар бит әле!Инде эшенә килсәк-күмәкләшеп эшләгәч,каз йолку бәйрәм сыйфатын алган.Кызларның осталары үзләренең булганлыкларын шунда күрсәткәннәр,башкалары алардан үрнәк алырга,өйрәнергә тырышканнар.Өмәгә килгән өлкәнрәк апаларның үткен күзләре исә,әлбәттә,кызларның кыланышларын,тотышларын күзәтеп,сынап фикер йөрткәннәр.

Шаян сүз,җыр,көлке белән аралашкан эш бик тиз барган.Хәер,кеше күп җыелганга күрә,эше артык озакка да бармаган.

Казларны юып кайтышка хуҗабикә каз маенда бик әйбәтләп коймак,я тәбикмәк пешереп,чәй әзерләп көтеп тора.Кайчак бу вакытка каз бәлеше дә пешеп чыга.Ләкин аш-бәлешләр кичен була.Монда инде кызлар белән рәттән башка кунаклар,егетләр дә чакырыла.Кичке мәҗлес тәмамлануга,шул йортта яшьләр уены оештырыла.Шуның өчен монда иң матур киемнәрен киеп,бизәнеп-ясанып киләләр.

Кичке табын булмаган очракта көндезге табын мулрак булган.Ләкин кичен кызларны эшне төгәлләү өчен-бу юлы каз мамыгын чистартырга дип чакырганнар.

## Корбан бәйрәм.

Гыйнвар аенда бөтен дөнья мөселмәннары корбан бәйрәмен билгеләп үтәләр.Ул бәйрәм мөселмән халкында иң зур бәйрәмнән санала.Бу бәйрәмдә корбан чалалар.Ураза беткәч,корбан бәйрәме 70 көннән соң була.Мөселмән календаре буенча 12нче айда үтә.Бу бәйрәм зуль-каада аенда бетеп,зөль-хиджә аенда башлана.Бу айда Мәккәгә һәм Мәдинәгә хаҗгә баралар.Бу вакытта 2 млн. кеше Саудовская Аравиягә баралар.Бәйрәм намазын укырга меңнән артык мөселмәннәр төрле мәчетләргә намазга җыеналар.Намаздан соң корбан чалу башлана.Бәйрәм көне кояш батканчы үтә.Корбан итен 3/2 хәерче ятимнәргә таратырга тиеш.Бу көннәрдә үз якыннарыннан бәхиллек кичерүләрен сорарга тиеш.Бу көн бәйрәм көне генә түгел,бу алладан гөнаһларын кичерү сорарга тиеш.Мәчеттә намаз укыганнан соң сәдака тараталар,соңыннан туганнарың,дусларының хәлен белешәләр.Корбан чалырга,дөя,сыер,буйвол,сарык,кәҗә рөхсәт ителә.Сарык,кәҗә- бер еллык,буйвол,сыер- ике еллык,дөя- биш еллык булырга тиеш.

Корбан бәйрәменә Ибраһим үзенең малаен корбан итәргә ризалык бирә.Азакы минутта алла, малайны жәлләп, сарык биреп Җәбраилгә җибәрә.Шулай итеп Абрамның малаен саклап кала.Корбан чалган кеше оҗмахка керү өчен нечкә-сират күперен,үткен кылыч,кайнар учак аша үтәргә тиеш.Бу көннәрдә зиратка бару, җыештыру, хәер бирү каралган.



## Ураза бәйрәме.

Ураза бәйрәме рамазан аеннан соң 1-е шавале ай календаренең 10 аенда була.

Мөселмән кешесе уразадан соң хәер өләшергә тиеш,аны ризык белән яки акча белән бирергә була.Бәйрәм 3 көн дәвам итә.Шул вакытта кешеләр кунакка йөриләр,кунак чакыралар,кайчакта гөнаһларыннан арыну өчен корбан чалалар,сарык,кәҗә,дөя рөхсәт ителә.Хәер бирү көчләү яки мәчет кушуы буенча түгел,үз теләген белән башкарылырга тиеш.



Урыссу мәчете “Мухтасибат”



“Кол Шәриф мәчете”

## Соңгы сүз.

Милли бәйрәмнәр онытыла бару сәбәпле, бер-беребез белән аралашу, очрашу, күрешүләр һаман сирәгәя, хәтта авыл җирендә дә бер-берсен белмәүчеләр бар хәзер. Бәйрәм көннәрендә бергәләшеп, туйганчы җырлашып утыруларның, биешүләрнең рәхәтлеге, ләззәте өлкәнрәк апа-абзыйлар, әби-бабайлар хәтерендә генә саклана. Ә бит мөкатдәс бәйрәмнәребез авыр фаҗигале елларны җиңелрәк кичерергә ярдәм итте, күңелләребезне җылытты, өметләребезне өзмәскә булышты. Кызганычка каршы, хәзерге яшьләрнең күбесе мондый шатлыклы, йөрәккә ял бирә, рухыбызны нечкәртә, кешеләрне якынайта һәм берләштерә торган чаралардан мәхрүм. Әллә шуңамы инде, яшьләребез туган-үскән җирләрен җиңел генә ташлап китә башладылар.

Шунысы аяныч, бүгенге көндә әби-бабаларыбыз да борынгыдан килгән күп кенә бәйрәм күренешләрен хәтерләп үк җиткермиләр. Чөнки аларның яшьлегенә шул бәйрәмнәребезне, милли гореф-гадәтләребезне җимерү, бетерү еллары туры килгән. Әлбәттә, авылларда искиткеч зиһенле, матур итеп сөйләп бирә белгән өлкәннәребез дә бар әле. Алар исән чагында, белгәннәрен язып алып каласы, саклыйсы иде...

Шуны да истә тоту зарури. Тормыш шартлары үзгәрү бәйрәмнәр дөньясын да үзгәртә. Бу — табигый. Шуның өчен дә теге яки бу бәйрәмне, йоланы түкми-чәчми генә, элеккечә үткәрергә тырышу, әлбәттә, дөрес түгел. Безгә бәйрәмнәребезне, аларга нисбәтле аерым йолаларның сәламәт, халыкчан рухын кайтару кирәк. Гомуми бәйрәмнәр оештырганда әзер «сценарий» көтеп утырмау, аны үзең табу, импровизацияләү мөһим.